СОВЕТ НОВОКИНЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
улица Советская, д.10, с.Новый Кинер,
Арский муниципальный район, 422031

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЕНӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 10 нче йорт, Яңа Кенәр
авылы, Арча муниципаль районы, 422031

Тел.,факс (84366)9-12-65, (84366)9-12-68, 9-12-60. E-mail: Nkin.Ars@tatar.ru

# РЕШЕНИЕ

**«14» июль 2026 ел** **№ 34**

## Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлегенең ирекле халык дружинасы төзелергә һәм үз эшчәнлеген гамәлгә ашырырга мөмкин булган территория чикләрен билгеләү турында

“Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, “Җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында” 2014 елның 02 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлегенең ирекле халык дружинасы төзелергә һәм үз эшчәнлеген гамәлгә ашырырга мөмкин булган, үз эченә Яңа Кенәр Яңа Ашыт, Сөрде, Югары Оры, Түбән Оры, Кызыл Яр, Шурабаш, Шура, Байкал, Яңа Сәрдә авылы торак пунктларын алган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кенәр авыл җирлеге чикләрен территория чикләре дип билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кенәр авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип таныйрга:

- “Халык дружинасы эшчәнлеге территориясе чиген билгеләү турында” 2014 елның 17 декабрендәге 112 номерлы;
- “Яңа Кенәр авыл җирлеге Советының “Халык дружинасы эшчәнлеге территориясе чиген билгеләү турында” 2014 елның 17 декабрендәге 112 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында” 2018 елның 07 февралендәге 75 номерлы.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы Ә.Ә.Гайфуллин